ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.07.2026 953 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру тәртибе турында» 2024 елның 25 декабрендәге 2206 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Граждан кодексы, РФ Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законы, РФ Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары, «Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алуга дәүләт хокукларын тәэмин итү өлешендә гражданнарның хокукларын яклау турында» 2013 елның 10 сентябрендәге федераль мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең 01-50-377/11-555 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләүне билгеләүнең якынча тәртибен гражданнар һәм юридик затлар өчен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмалары уставлары нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру тәртибе турында» 2024 елның 25 декабрендәге 2206 номерлы карары белән расланган түләүле хезмәтләр күрсәтүне оештырганда гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазифаларының якынча исемлегенә һәм тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

«2. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, расланган керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә хезмәткә түләүгә җибәрелә торган эшчәнлекнең эшкуарлык һәм башка кеременнән акчалар исәбеннән, югарыда күрсәтелгән бурычларны үтәгән өчен, түләүле (шул исәптән мәгариф) хезмәтләрнең барлык төрләре буенча аерым бер чорда керә торган акчаларның гомуми суммасыннан 10 % күләмендә айлык өстәмә түләү билгеләргә;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4C332AC224D0671AE6BDE7AE77479904

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 02.02.2026 до 28.04.2027

Э.Р. Әхмәдиева